# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

19 ноябрь 2021 ел № 1

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге составына керүче Түбән Чыршылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 19 ноябрендә уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: «2022 елда һәр балигъ булган гражданнан 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?", Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге Түбән Чыршылы торак пункты территориясендә теркәлгән 1 Төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү дә керә:

1) Түбән Чыршылы авылы зираты территориясен киртәләп алу өчен төзелеш материаллары сатып алу;
2) Түбән Чыршылы авылында Питрау, өлкәннәр көне үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;
3) МТЗ-82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;
4) “Сарман” район газетасында некролог бастыру.

«ӘЙЕ ЮК»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 37 кеше, халык җыенында катнашучылар саны 25 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 25 кеше тавыш бирде;

«юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре - чын мәгънәсендә.

2. "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлеге Түбән Чыршылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 2022 елда

500сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне үтәүгә жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме?:

1) Түбән Чыршылы авылы зираты территориясен киртәләп алу өчен төзелеш материаллары сатып алу;

2) Түбән Чыршылы авылында Питрау, өлкәннәр көне үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;

3) МТЗ-82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;

4) “Сарман” район газетасында некролог бастыру.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Югары Чыршылы авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән,Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http: //pravo.tatarstan.ru., Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http: //sarman.tatarstan.ru. кабул ителгәннән соң җиде көн эчендә игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы И.Н.Камалетдинов